Николай Туганов фотоэтюды.



# Якты сагыш

Бу җиргә һәр кеше үз сагышын җыярга килә. Берәүләр ак биләүдә чактан башлап гомер буйларына күңел төпкеленә тамчылап саркылган ул сагышны, матур бизәкләргә әйләндереп, кешеләргә тарата. Андыйлар сирәк. Андыйларга дөньялыкта сагыш та мулдан бирелә ахрысы. Мә, бәгырең иләге аша үткәр дә, иң җете төсләрен кешеләргә тарат, аларның тормышын гамь белән бает, дигәндәй.

Татар илендә Рәшит Бәшәр дигән шагыйрь бар. Язучы ич ул, тормышчан повесть-хикәяләр, балалалар өчен әсәрләр, шактый җырлар авторы, диярсез. Әйе, тик, минемчә, Рәшит Бәшәр язган һәр әсәр – шигырь. Моңлы, сагышлы шигъри гомернең сәхифәләре алар. Бу язмамда җитмешен тутырып килүче ил агасының гаҗәеп бер шигырьгә тиң гомер юлына күз салмак булдым. Сәяси, иҗтимагый тормышның кискен үзгәреш чорларында яшәгән, ил-көннең катлаулы чакларына шаһит булган һәм шул дәверләрдә үз юлын таба белгән әдипнең гомер сәхифәләрен берничә кәгазь битенә сыйдыра алу, гәрчә, мөмкин эш булмаса да.

...Сугыштан соңгы ач-ялангач ил. Яланаяклы, ачлы-туклы балачак. Пилорама эшендә гариплэнгән сыңар куллы әнкәй һәм энекәш. Сыңар канатлы сабыйлык. Әмма туган туфракның, туган телнең буыннарны һәм бәгырьләрне ныгытырлык суты бар. Баштан сыйпап үткән авыл агайлары бар, күктә йолдызлар, сукмакларны еракларга илтә торган олы юллар бар. Ә капкалар ачык. Бу хакта әле нәни Рәшит бераз үскәч, Мәскәүдә укыган чакларында язар. Һәм аның язганнарын авылдашлары кулдан-кулга йөртеп, кичләрен капка төпләрендә көлешә-көлешә укырлар.

Шагыйрь тарихы нидән башлана соң? Шагыйрь булуыңны аңлаган мизгелдәндер, мөгаен. Кукмара районы Яңил урта мәктәбенең 6 сыйныф укучысы Рәшит Бәшәров кечкенәдән шигырьләр яза. Яза да, ертып ташлый. Аның каләм тибрәтүен – шагыйрьлеген әле беркем дә белми. Үзеннән кала. Рәшит шуны яхшы аңлый: ул язарга тиеш. Һәм ул яхшы язарга тиеш. Ниһаять, кыюлыгын туплап, беренче язмасын «Яшь ленинчы»га җибәрә – бастыралар. Аннан икенечесен, өченчесен... Гәҗит битләрендә үз исемен күреп канатланган малай, тагы да үҗәтләнеп, матбугатны «яуларга» керешә. Дөнья күргән һәр язмасын пөхтәләп альбомга теркәп барырга да онытмый. Кечкенәдән китап «җене» кагылган Рәшит басма сүз кадерен нык аңлый. Шул рәвешчә би-

ография язылы башлый. Шагыйрь гомере тарихы. Шунысы тәгаен, Рәшит абый – үзенең каләм остасы буласын кечкенәдән тойган, бөтен җаваплылыгы белән үз миссиясен бәләкәйдән аңлап кулына каләм алган сирәк затларның берсе.

...Студент еллар. Авыл капкасы аръягындагы серле дөнья үзенә дәшә. «Укырга керә алмаячаксың, барып та йөрмә!» дигән үгетләр яшь күңелне кыздыра гына. Үзе белән ике иптәшен – Рамил белән Сашаны да ияртеп, Рәшит Казан университетына юл ала. Ни гаҗәп, өчесе дә авылга студент билеты белән кайта алар. Әйе, атаклы галим Ибраһим Нуруллин көчле төркем туплый ул елны. Киләчәктә татар сүз сәнгатенә Рәшит Бәшәр, Зиннур Мансуров, Рашат Низами, Рушания Низамова, Альберт Сафин, Нәҗибә Сафина һ.б. кебек язучылар үстерәчәк төркем була ул. Берничә елдан чал чәчле остаз, тәрәзә янәгына сөялеп уйчан гына папирос көйрәткән хәлдә, хәйләкәр елмаеп әйтер: «Уларым, мин бит сезнең җидегезне рус теленнән «икеле» белән алдым». «Кемнәр ул?» – дип кызыксынган күзлекле студентына җавабы кыска булыр Ибраһим аганың: «Кирәкми, Рәшит улым, барыгыз да язучы булып беттегез инде».

Язучылык. Миссия, шөгыль, җан авазы... Ә тормыш дигәннең мең мәшәкате көтә, шәхеснең оя корасы, алмаш үстерәсе, мең табасы һәм мең югалтасы бар бит әле. Кем белә, бәлки башкаланың берәр газета-журнал редакциясендә эшкә калса, Рәшит Бәшәр дигән әдипнең кадере зуррак булыр иде дә, исеме ераграк яңгырар иде. Хәер, киресенчә дә булырга мөмкин... Һәркемнең үз юлы – үз язмышы. Тормышның үзенә тиң гамьле әсәрләр язар өчен, юллар кирәк, аклы-каралы борылышлардан үтү кирәк. Милләт хиссиятен аңлыйм дисәң, төрле төбәкләрдәге кардәшләр белән аралашу, аларның көнитешен аңлау зарур. Татар – Казанда гына түгел. Үзәктән читтә яшәгән милләттәшләрнең гадәт-көнитеше, дөньяга карашы, үзаңы һәм зәвыгы бөтенләй башка ләбаса. Милләт өчен язасың икән, милләтне белү кирәк.

Университетның татар бүлеген тәмамлаган яшь белгеч, юллама белән, Лениногорск районына мәктәпкә эшкә китә. Үзе генә түгел. Янында – Казан пединститутын тәмамлаган математик хатыны Люция бара, биләүдә нәни улы Ринат мес-мес йоклый. Люция – Рәшитнең янәшәсендә чәчкә аткан бәхете. Сыйныфташлар булып ничәмә еллар бер сукмаклардан узган ике яшь йөрәк гомер юлыннан җитәкләшеп атлый хәзер. Ә бит күптәнме математика дәресендә укытучы тактә алдына гел бергә чыгара иде аларны. Кара тактаны кыл урталай бүлеп, икесен ике якта мәсәлә чиштерә иде. Люциянең һәр мисалны чикләвек ватkандай тиз генә «хәл итүен» Рәшит авыз ачып карап тора иде. Тормышта да, Рәшите җанындагысын кәгазь битләренә күчерсен, язучы булып танылсын өчен, күп кенә көнитеш мәсьәләләрен үзенә чишәргә туры килер Люциягә. Ул сынатмас, Рәшитнең тылы нык булыр. Каләм әһеле өчен ярты бәхет бу.

Язмыш яшь гаиләне Лениногорск якларында озак тотмас. Бераздан, кызлы да булып, Чаллы каласында төпләнерләр. Ә Чаллы ул елларда талантларга канат куя белә. Заводка эшкә урнашкан Рәшитне дә кунак-

чыл кабул итә ак кала. Иң кадерлесе – мохит бар: Кадыйр Сибгатуллин, Фаяз Дунай, Рахмай Хисмәтуллиннар биредә. Мөдәррис Әгъләм еш кына кунакка килә. Җандашлар, аркадашлар янәшәдә, гөрләшеп-аралашып яшәгән чаклар – ишекләр бикләнми торган, тәрәзәләр ачык, күңелләр дә җилбәгә чорлар. Берничә елда торак мәсьәләсе дә хәл ителә. Эшләгән кеше ашлы булган дәверләр шул. Кул көченңне һәм йөрәк ялкынынңны кызганма гына!

Төнге смена эшләп, автобуста кайтып килүче Рәшитнең күңеленә бер җөмлә килә: «Иртәгә дә яшисе бар!» Көне буе бимазалый, тынгы бирми бу сүзләр. Чаллы урамнарына төн караңгысы сарылгач, ир, бүлмәсен эчтән бикләп, язу өстәле артына килеп утыра. Башта шул бер җөмләдән гайре берни юк. Ә кул яза, күңел яза. Иртәгесен эшкә җыенган хатынын: «Мин повесть яздым!» – дип таң калдыра Рәшит. Әнә шулай, тилерепкотырып, үзен-үзе аямый, төннәр буе яза ул. «Иртәгә дә яшисе бар», «Ачык капка», «Җилдә тибрәлүче бишекләр», «Акбалык», «Минем әтиемне сугышта үтерделәр» һ.б. повестьлары әнә шулай языла. Заводта, тимер арасында тәүлекләр буе кайнап эшләгәннән соң, бәгыреннән җиләс, якты сагыш бөрки торган әсәрләре түгелә Рәшит Бәшәрнең – тормыш үзе язган әсәрләр.

...Аксакал каләмдәшемнең фатирына аяк басам. Гап-гади йортның икенче каты. Бернинди купшылык, «ялтыравыклы» вак-төяк юк. Әмма эш бүлмәсен ачып керү белән, аһ итеп, дивар буенча тезелгән киштәләрдән күзем ала алмый, гаҗәпләнеп торам. Үземне әкияткә эләккәндәй хис итәм. Алай гынамы, китапларның күплеге, алардан бөркелгән мәгърур затлылык алдында үземне бик кечкенә бер җан иясе итеп тоеп, сак кына түргә узам. Ул арада өстәлдәге язу машинкасын, агач өстәл-урындыкларны, пөхтәләп тезелгән альбомнар киштәсен шәйлим. Бу әкияти «дөнья»да әдәбият, шигърият яши, биредә язмышлар языла.

Рәшит абый, гадәтенчә елмаеп, тыйнак кына әңгәмә кора. Үз шәхесе, тормышы турында тыелып-тартынып кына телгә ала ул, сөйләменең җеп очы – милләт, тел мәсьәләсе. Күзләре сагышлы, сагышлы... Хәер, балалары, оныклары турында сөйләгәндә, бу күзләрдә кояш нурлары бии. «Китап укып үстеләр. Алар гына түгел, йортыбыздагы бөтен бала-чага китап алырга миңа керә иде. «Рәшит абый, китабың арасыннан акча чыкты», дип кире кертүннәре дә булды», ди ихлас көлеп. Җай гына әңгәмәдәшемнең хатирәләренә кагылам. Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укыган чаклары, аннан «Таң йолдызы», «Аргамак», «Мәйдан» басмаларында эшләгән еллары хакында сөйли ул. Бакыйлыкка күчкән аркадашлары-җандашларының исемнәрен кадерләп телгә ала. Сагынып, зарыгып акрын гына сөйли. Мин аның сөйләвендә шомырт чәчкәләре шавын, агач капка ыңгырашуын, төзелешләр гөрелтесен ишетәм, кәгазь аклыгын, сүзләр сафлыгын тоям, хөрлек хисен һәм читлек хиссиятен, мәхәббәт сулышын һәм югалту ачысын шәйлим. Мин Рәшит Бәшәр Сүзендә чорлар сагышын тоям.

**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА**